ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ _121_

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_25_» _октябрь,_ 2023 ел

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч түләвенә ышанычсыз дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга;
2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясенең 2023
елның 25 октябрендәге 121
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан, Россия Федерациясе бюджет системасы керемнәренең баш администраторы (администраторы) буларак (алга таба – Инспекция), Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләргә ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели.

2. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерүгә түбәндәге очракларда өметсез дип таныла:

1) физик зат – бюджетка түләүләр түләүче зат вафат булганда яисә Россия Федерациясенең граждани-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгәндә;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә бюджетка түләүләрне түләүче шәхси эшкуар – түләүчене банкрот дип тану – әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә;

3) шәхси эшкуар булмаган гражданинны 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип тану – әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә;

4) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – бюджетка түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

5) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә;

6) суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ

номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм түләттерүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр бурычның барлыкка килү датасыннан башлап биш елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме бурычлы затка карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

бюджетка түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш туктатылганда;

7) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.

2.1. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип таныла.

3. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

1) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Инспекция хисаплылыгыннан өземтәләр (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта);

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында Инспекция белешмәләре;

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерүгә ышанычсыз булуын тануның әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән очракларын раслый торган документлар.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

физик зат – түләүченең вафат булуын таныклый торган яисә аның вафат дип игълан ителүе турында дәлилләүче документ.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – бюджетка түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – бюджетка түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ.

Шушы Тәртипнең 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә гражданин – бюджетка түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бюджетка түләүләр түләүче оешманы бетерү белән бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар булган документ.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары.

Шушы Тәртипнең 2 пунктындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча производство эшчәнлегенең тәмамлануы һәм производство документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе сәбәпле суд приставы-башкаручысы карары күчермәсе;

бөлгенлек турында эш буенча эш кузгату өчен нигезләр юклыгы турында белешмә;

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат – бюджетка түләүләр түләүчене теркәүче орган карары буенча әлеге реестрдан төшереп калдыру турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ; 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару эшчәнлеген тәмамлау турында карар.

Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган нигезләр булганда:

Административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар.

4. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар Инспекция тарафыннан

даими нигездә кимендә биш кешедән торган активлар керү һәм чыгу буенча комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан кабул ителә.

Комиссия составы Инспекция җитәкчесе боерыгы белән раслана. Комиссия составына комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары керә. Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, комиссия утырышларын әзерли, комиссия утырышына кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларына хәбәр итә, шул исәптән комиссия утырышларын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында аларга вакытында хәбәр итә һәм комиссия әгъзаларын кирәкле материаллар һәм документлар белән тәэмин итә.

5. Тәртипнең 3 пунктында каралган документларны теркәп, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип таныга тиешлек турындагы мәгълүмат расланган документларны алган вакыттан алып бер ай дәвамында Инспекциянең структур бүлекчәләре җитәкчеләре тарафыннан Комиссиягә җибәрелә.

6. Инспекциянең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турындагы белешмәләре раслаучы документлар алынганнан соң бер ай эчендә Инспекциянең структур бүлекчәләре тарафыннан Комиссиягә җибәрелә.

7. Инспекциянең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча исәпкә алына торган бурыч суммалары турындагы хисапларыннан өземтәләр Комиссиягә финанс хисабы һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан аларны алганнан соң биш эш көне эчендә җибәрелә.

8. Комиссия, зарурлык килеп туган саен, әлеге Тәртипнең 5, 6 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат һәм документлар Инспекциясенең структур бүлекчәләреннән алынганда, ләкин кварталга бер тапкырдан ешрак булмаган күләмдә утырышлар уздыра.

9. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының өчтән ике өлеше булса, Комиссия үз функцияләрен башкарырга хокуклы.

Комиссия карарны комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче затның тавышы хәлиткеч булып тора.

Инспекциянең структур бүлекчәләреннән кергән көннән алып җиде календарь көннән дә соңга калмыйча документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга;

б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танудан баш тартырга. Әлеге карар Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карауга комачауламый.

10. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты Комиссия

утырышын уздырганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия тарафыннан әзерләнә.

11. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар Комиссия утырышы көненнән алып өч эш көне эчендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

12. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында бәяләмә Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта));

б) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик затның салым түләүчесенең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

в) бурычны барлыкка китергән түләү турында белешмәләр;

г) шуның буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәрен классификацияләү коды, аның атамасы;

д) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның суммасы;

е) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул ителү көне;

з) Комиссия әгъзаларының имзалары.

13. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы бәяләмә Инспекция җитәкчесе тарафыннан раслана.

14. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы бәяләмә бурычны бюджет системасыннан (бухгалтерлык исәбеннән) һәм Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасында исәптән чыгару (яңарту) өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында бюджет керемнәренең баш администраторы (администраторы) буларак Инспекция хисапнамәсеннән
20__елның "__"______ №___ өземтә

| т/с | Бюджет классификациясе коды | Бурычлы затның исеме | Бурыч барлыкка килгән көн | Нигезләүче документ реквизитлары | | | Бурыч суммасы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Атамасы | Дата | № | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | Җәмгысе: | |

Финанс исәбе һәм
хисаплылык бүлеге җитәкчесе ____________/________________________/
(имза) (инициаллар, фамилия)